ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Кыр Шонталы авылы

03.11.2022 № 9

**Гражданнар милкенә торак фондыннан алар били торган торак урыннарын тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (торак фондын хосусыйлаштыру) раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып

**карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлегендә гражданнар милкенә торак фондыннан алар били торган торак урыннарын тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (торак фондын хосусыйлаштыру)расларга(кушымта).

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.12.2021 ел, № 22 “Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында», Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://alekseevskiy.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталы авыл җирлеге Советы бинасындагы махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Кыр Шонталы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Г.Н.Киямова**